**СОВЕТ ЧЕПЧУГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422736, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Чепчуги, ул.Советская, 1

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЫПЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422736, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чыпчык авылы, Совет ур.1

Тел./факс: +7(84365) 72-5-01, e-mail: Chep.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ**
**21 апреля 2021 г.**

**КАРАР**
**№ 26**

**Советның 2019 елның 31 июлендәге 123 нче номерлы Карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Чыпчык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 июлендәге 123 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәнең (Советның 30.09.202020 № 4 карары редакциясендә) 3 бүлегенең 3.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле 16 һәм 17 пунктлар белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«16) участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү;

17) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.Р.Җиһаншин

Чыпчык авыл җирлеге Советы
Совет Чепчуговского сельского поселения
ИНН 1616004928